**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Югары Чура авыл җирлеге башлыгы карары**

**2021 елның 12 ноябре** **№ 6**

**«Кукмара муниципаль районы Югары Чура авыл җирлегенең Пчеловод авылы торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Югары Чура авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2021 елның 25 ноябрендә 14 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Югары Чура авыл җирлегенең Пчеловод авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын үткәрүне билгеләргә.
   Гражданнар җыенын Пчеловод авылы, Центральная урамы, 24 йорты адресы буенча урнашкан авыл клубы бинасында үткәрергә.

2. 2021 елның 25 ноябрендә 15 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Югары Чура авыл җирлегенең Пчеловод авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын үткәрүне билгеләргә.
   Гражданнар җыенын Пчеловод авылы, Центральная урамы, 24 йорты адресы буенча урнашкан авыл клубы бинасында үткәрергә.
3. 2021 елның 25 ноябрендә 16 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Югары Чура авыл җирлегенең Пчеловод авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының өченче этабын үткәрүне билгеләргә.
   Гражданнар җыенын Пчеловод авылы, Центральная урамы, 24 йорты адресы буенча урнашкан авыл клубы бинасында үткәрергә.

4 Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «Көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, I төркем инвалидлары һәм шулай ук 80 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк затлардан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Югары Чура авыл җирлегенең Пчеловод авылы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2022 елда үзара салымны 500 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны

түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Пчеловод авылында урамнарны яктырту өчен энергия саклаучы лампалар сатып алу, урнаштыру, яктырткычларны, махсус җиһазларны ремонтлау; килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү;

- Пчеловод авылында артезиан скважиналары өчен насослар сатып алу; килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү;

- Пчеловод авылы чишмәсен төзекләндерү; проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру; килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү;

- Пчеловод авылы зиратын коймалау өчен материал сатып алу; килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү;

- Пчеловод авылының урам юл челтәрен карап тоту (юлларны кардан чистарту һәм территорияне җәй көне чабу; ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

- Пчеловод авылында видеокамералар сатып алу һәм урнаштыру; килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү;

- Пчеловод авылының Лесная урамында асфальт җәю һәм вак таш җәеп ремонтлау; проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү;

«РИЗА» «КАРШЫ»

5. Гражданнар җыенын үткәрү өчен, торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча (урамнар буенча) бүләргә.

6. Халык җыенның үткәрүгә җаваплы итеп Югары Чура авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

7. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

8. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Югары Чура авыл җирлеге башлыгы: В. Н. Андреев